**Юсупова Ә.Ш.**
**Денмөхәммәтова Э.Н.**

# МӘДӘНИЯТАРА БӘЙЛӘНЕШЛӘРДӘ КЫТАЙ ТАТАРЛАРЫ

(тикшеренүләр РГНФ 11-04-00074 а грантына нигезләнеп башкарыла)

Хәзерге вакытта татар теленең Ерак Көнчыгышта да кулланылышта булуы - куанычлы күренеш. Аны төрле яклап өйрәнү һәм тикшеренүләрне фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү исә, чит төбәкләрдә яшәүче татар халкының тормыш-көнкүреше турында тулаем күзаллау тудыру өчен, төп чыганак булып тора. Көнчыгышта яшәүче татар диаспорасы телен Кытай татарлары, аерым алганда Шенҗан-уйгыр автоном районындагы милләттәшләребез теле мисалында өйрәнү бу юнәлештә чираттагы гамәл булып санала. Андагы татар-уйгыр һәм татар-кытай икетеллелеге үзенчәлекләрен үз эченә алган лексикографик материал өйрәнелмәгән диярлек, шунлыктан бу гамәл татар лексикологиясенең теоретик юнәлешен баетуда да ярдәм итәр дип саныйбыз.

Кытайның төп татар үзәкләре булып, Голҗа, Өремче, Чүгүчәк шәһәрләре исәпләнә. Нәкъ менә әлеге шәһәрләрне көнчыгыш эмиграциядәге милләттәшләребезнең туплану һәм чын татар тормышы белән яшәү урыннары дип атап була. Анда туган ил мохите, “татар цивилизациясе» сакланып калган, ягъни кабатланмас мәдәни тирәлек булдырылган.

Кытай шәһәрләре күпмилләтле, шуңа да карамастан, Голҗа, Өремче, Чүгүчәктә татар теленең төп кулланылу өлкәләре дип түбәндәгеләрне атарга мөмкин:

1. XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында, иң беренче чиратта, бу шәһәрләрдә татар теле – мәгариф теле буларак яши. Голҗа, Өремче, Чүгүчәктә башлангыч һәм урта белем бирү мәктәпләрендә укыту татар телендә алып барылган. Моны татар уку йортларының исемнәре үк дәлилләп тора: татар мәктәбе, кызлар мәктәбе, “Нур” мәктәбе, Гөләндәм ханым мәктәбе, “Максудия” мәктәбе, Гомәрия мәктәбе. Татар мәктәпләрендә татарлар гына түгел, уйгыр, казах, үзбәк, дунган һәм кытайлылар да белем алган.

2. Татар теле эшлекле сөйләм теле һәм язма аралашу теле буларак кулланылган. Голҗада эшлекле аралашу элеккеге Россиядәге инфраструктураны хәтерләтә: документлар төгәл алып барылырга һәм катгый калыплар нигезендә төзелергә тиеш. Шунлыклар мондый эш кәгазъләрендә борынгы гыйбарәләр һәм катып калган формалар әлегә кадәр сакланып калган.

3. Татар теле хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә киң кулланыла. Татар эшмәкәрләренең 60 кибетендә сату-алу, шулай ук көнкүреш, транспорт, юридик хезмәт күрсәтүләрнең татар телендә алып барылуын "Алга" газетасыннан алынган күпсанлы белдерүләр, шул исәптән шәһәрнең адреслар һәм белешмә китапларында теркәлгән мәгълүматлар тагын бер кат раслый. Почта хезмәте күрсәтү дә татарча башкарылган.

4. Татар Голҗасының мәдәни тормышы, зур булмаган провинциаль шәһәр өчен, искиткеч бай. Революциягә кадәрге чорда Россиядән мәдәният һәм сәнгать зыялыларының күпләп Кытайга күчеп килүе аеруча Өремчи һәм Голҗа шәһәрләренең мәдәниятенә уңай йогынты ясаган.

5. Татар китапханәләренең фондлары аша эмигрантларга татар мәдәнияте һәм китабы белән танышу мөмкинлеге тудырылган. Китапханәләрдәге татар язучыларының әсәрләрен һәркем укый ала. "Мөкәммәл хисап", "Гомуми тарих", "Халык тарихы" кебек һ.б. дәреслекләр татар телендә басылган. 1947 елда Голҗа шәһәрендә Г. Тукайның шигырьләр җыентыгы басылып чыккан.

6. Татар колонияләре оешканнан башлап, Өремче, Голҗа һәм Чүгүчәк шәһәрләре җирлегендә татар топонимнары өстенлек иткән. Моның ачык мисалы дип, шәһәр урамнарының татарча аталуын, яисә атамаларның татар урбанимикасы нигезендә ясалуын күрсәтергә кирәк. Мәсәлән, Нугай город, Ташләпкә базары, "Алтай" ширкәте, "Тьян-Шан" ширкәте, Гали бакчасы, Нугай дамелла багы, Тукай күчәсе, Хәбип Юни күчәсе, Нугай мәчете, татар зираты һ.б. Татар урамнары, кибетләре һәм кунакханә исемнәреннән тыш, татар

телендәге төрле белдерүләр һәм рекламаларны да монда еш очратырга мөмкин (“Мәрхәбә татар тамаклары”).

7. Татар теле – Голҗа һәм Өремче мөселман шәһәрләрендә дин теле дә булып саналган. Голҗа һәм Өремчедә татар мәчетләре эшләгән (татар мәчете, нугай мәчете), мөселман календаре алып барылган. Мәчетләрдә гыйбадәт кылу - гарәп телендә, үзара аралашу татар телендә барган. Голҗада дини әдәбият һәм мөселман вакытлы матбугаты басмалары татар телендә чыгарылган. Моннан тыш дини жанрдагы хезмәтләр (дини вәгазьләр һ.б.) дә татар телендә язылган.

8. Голҗа һәм Өремче шәһәрләрендә татар теленең төп кулланылу өлкәсе, әлбәттә, көнкүреш мохите булган. Гаиләдә аралашу һәм үз кавеме кешеләре белән рәсми булмаган сөйләшүләр татарча барган. Бу исә төп этник үзенчәлек булып тора һәм этник үзбилгеләнешне күрсәтүче чара булып исәпләнә. Голҗадә яшәү өчен, дәүләт теле булган кытай телен белү мәҗбүри түгел, үз туган телеңне һәм уйгыр телен белү дә бик җитә.

Шулай итеп, көнчыгыш татар эмиграциясе үзәкләре булган Өремче, Голҗа һәм Чүгүчәк шәһәрләрендә тормыш-көнкүреш тулысынча татар традицияләренә нигезләнеп һәм ислам кануннары нигезендә алып барылган. Чит илдә булуына һәм җирле халык сан ягыннан күпкә артык булуга карамастан, Кытайда татар теле көнкүрешнең төрле өлкәләрендә актив кулланылган.

Күпмилләтле Голҗа һәм Өремче шәһәрләрендә башка милләт вәкилләре дә үз телләрен һәм мәдәниятләрен саклап калганнар. Мәсәлән, уйгыр, казак, узбәк, кыргыз һ.б.халыклар, ләкин алар арасында татар теле өстенлек иткән.

Күпмилләтле дәүләтләрдә тел сәясәте алып бару аеруча катлаулы чара булып тора. Татар һәм кытай телләре мисалында шуны әйтергә мөмкин: кытай теле – рәсми Дәүләт теле, төп җирле халык теле. Татар теле исә - “килмешәк” булуына карамастан, Кытайда, аеруча Голҗада, киң кулланылыштагы тел. Алда әйтелгәнчә, анда җәмәгать эшләре татар телендә алып барылган.

Кытай территориясендә яшәгән татарларга һәм башка халыкларга карата дәүләтнең мөнәсәбәте уңай. Татар телендә сөйләшү беркайчан да тыелмый,

кытай телен белү мәҗбүри саналмый. Күпмилләтле халыкларны үзара дус-тату яшәтү өчен, дәүләт тарафыннан төрле ташламалар ясала. Болар барысы да Кытай хөкүмәтенең җирле булмаган халыкларга карата булган сәясәтенең лояль булуын кабаттан раслый.

Кытай татарлары телендә түбәндәге тел күренешләрен күзәтергә мөмкин.

Хәзерге татар әдәби телендә сөйләшүче күзлегеннән чыгып караганда Кытайда яшәгән татарлар телендә искергән сүзләр (чаралар) күп булуы ачык сизелә. Ягъни көнчыгыш төбәк татарлары телендә революциядән соң Советлар Союзы территориясендә яшәгән татарларның теленнән төшеп калган сүзләр актив кулланылышта йөри. Мәсәлән, *клит* (ключ-ачкыч), *кулуп* (замок-йозак), *тәтә* (мама-әни) *эттә* (папа-эти) *бакали* (бакалия), *чөмәк* (гвоздь-кадак), *кат-кат* (пирог), *бал прәннек* (пряник), *чыраг* (свет-ут), *табанча* (пистолет), *чапан* (куртка). Димәк, “искергән сүз ” төшенчәсе күп кенә лексик берәмлекләр, грамматик формалар һәм синтаксик төзелмәләр, дөрес әйтү һәм язу нормалары өчен катгый “чара” түгел, бу берәмлекләр Кытай татарлары телендә бүгенгәчә киң кулланылалар.

Кытай татарлары теле әйтелеше һәм мәгънәсе ягыннан охшаш уйгыр сүзләре исәбенә баетылган (*тоху* (курица-тавык), *хораз* (петух-әтәч), *кунак* (кукуруза), *мумай* (бабушка-әби), *чал* (старик-карт), *пияз* (лук-суган), *сябез* (морковь-кишер), *гөреш* (рис-дөге), *нахша* (песня-җыр), *кой* (овца- сарык), *учкә* (коза-кәҗә), *мөшек* (кот-песи), *пайпак* (носки), *юллык* (гостиниц-күчтәнәч). Шулай ук, көнбатыш-европа һәм урыс телләреннән кергән сүзләр дә шактый күп: телефон, телевизор, компьютер, радио, малина (кура җиләге), варенье, батинка (ботинки), брука (брюки- чалбар), майка, кастум (костюм), шиблит, столба (столб-багана), падарка (подарок-бүләк), машина, автобус, вокзал, поезд, аэропорт, аэроплан, булка, кампит (конфета), консул һ.б. лар.

Голҗа, Өрөмче татарлары телендә кытай алынмаларын да очратырга мөмкин: *яңйу* (картофель-бәрәңге), *ляңпун* (китайское блюдо- кытай ризыгы), *лазы* (острый перец- ачы борыч), *бәсәй* (пекинская капуста-пекин кәбестәсе), *чәйзә* (баклажан), *луюоң* (магнитофон), *дийәнши* (телевизор), *биңшан*

(холодильник-суыткыч). Россиядән күчеп килгән эмигрантлар телендә кулланыла торган кытай алынмаларының составы кытай тормышының үзенчәлекләрен чагылдыра, алар татар тормышыннан ерак, татар кешесе өчен ят күренешләрне атау өчен кулланылалар. Кытай алынмаларын кабул итеп, татарлар үзләре өчен чит булган илнең көнкүреш һәм яшәешенең кайбер якларын үзләштергәннәр. Татар кешеләре һәм кытайлыларның Шенҗаңда интенсив аралашуларына карамастан, милләттәшләребез телендә кытай алынмалары күп түгел. Бу лингвистик һәм экстралингвистик сәбәпләр белән аңлатыла.

Шул рәвешле XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында Кытайда эмиграциядәге татарлар өчен, татар теле үзбилгеләнү күрсәткече була. Чит илгә күчеп килгән бу татар зыялылары максатчан һәм эшчәнлекләре, алдан күрә белү сәләтенә ия булулары аркасында, үз телләрен саклап кала алганнар һәм, дәүләт күләмендә ихтирамга ия булып, билгеле бер дәрәҗәләргә ирешә алганнар.

## Әдәбият

*Ахметова Я. М.* Сравнительно-историческое исследование языка татар Финляндии / Я.М.Ахметова. – Казань:КГЭУ, 2009. – 136 с.

*Госманов М.Г.* Ябылмаган китап / М.Г.Госманов. – Казан: тат.китап. нәшр., 1996. – 206 б.

*Чанышев М.К.* Кытайда татар мәгарифе тарихы / М. К.Чанышев. – Казан: “Җыен” нәшрияты, “Идел-пресс” нәшрияты, 2007. – 240 б.